**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05. 06. 2018 **г.Мензелинск** № 588

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район хосусыйлыгында булган мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләве һәм аның күләмнәрен билгеләү турындагы Нигезләмәләр турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль Законы, “Минзәлә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы, 25.06.02 елдагы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) объектлары турында”гы №73-ФЗ Федераль законы, шулай ук мәдәни мирас объектлары булган күчемсез милек объектлары белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Кушымта №1 нигезендә, беркетелгән “Муниципаль хосусыйлыкта булган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, кулланылмый торган мәдәни мирас обектларына карата ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибе турында Нигезләмә”не расларга.

2.Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

3.Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Финанс-бюджет һәм җир-милек палатасы Рәисе Л.И.Кондратьевага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын Башкаручы А.Г.Гатина

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты карарына
Кушымта №1
дата 05.06.18 № 588

Муниципаль хосусыйлыкта булган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, кулланылмый торган мәдәни мирас обектларына карата ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибе турында Нигезләмә

1.Гамәлдәге Нигезләмә ТР Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгына караган һәм тормышы канәгатьләнерлек булмаган, мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, мәдәни мирасның файдаланылмый торган объектларына карата ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – мәдәни мирас объекты).

2. Гамәлдәге Нигезләмәнең тәэсире Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) бердәм дәүләт реестрына кертелгән, ТР Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгына караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган, Россия Федерациясе хөкүмәте билгеләгән мәдәни мирас объектларына кертү критерийларына туры килгән мәдәни мирас объектларына кагыла.

3. Ташламалы аренда түләве торышы канәгатьләнерлек булмаган, ТР Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгына караган мәдәни мирас объектларына карата аренда килешүен төзү хокукына гражданлык, монополиягә каршы закон таләпләре нигезендә уздырылган аукцион нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

Аукционнар уздыру турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән сату (торги) уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Россия Федерациясенең рәсми сайтында урнаштырыла.

Еллык аренда түләвенең башлангыч (минималь) күләме мәдәни мирасның бер объекты өчен 1 сум дип билгеләнә.

Аукцион уздырылу турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән сату (торги) уздыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияле челтәрендә урнаштырыла.

Аукцион уздырылу турындагы мәгълүмат составында, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәгълүматтан тыш, түбәндәгеләр урнаштырыла:

а) арендага тәкъдим ителә торган мәдәни мирас объектының төп

характеристикалары (әлеге объектның техник торышын һәм 2014 елның 25 июнендә кабул ителгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында"гы №73-ФЗ Федераль законының 47.6 маддәсендә каралган сак бурычлары нигезендә аны саклау предметының тасвирламасын да кертеп)

б) аренда килешүе проекты;

в) мәдәни мирас объектын саклау буенча төп эшләр исемлеге;

г) арендаторның мәдәни мирас объектын саклау буенча бурычы (мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән 7 елдан артмаган срокта, мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен әзерләү һәм килешү срогын да кертеп, объектны арендага тапшырган көннән 2 елдан артмаска тиеш)

д) арендаторның арендага бирүчегә мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне билгеләнгән тәртиптә проект документациясе килешенгәннән соң бер айдан соңармыйча, мондый эшләрне уздыру өчен билгеләнгән тәртиптә проект документациясендә күрсәтелгәнчә, мәдәни мирас объектларын саклау буенча эш бәясеннән (35 процентттан ким түгел) чыгып, мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрне башкару бурычларына бәйсез гарантия алу һәм бирү

4. Ташламалы аренда түләве Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгына караган, канәгатьләнерлек булмаган хәлдә дип табылган мәдәни мирас объектына карата билгеләнә (арендатор Положениенең 3п.п. "г, д" пунктларында билгеләнгән бурычларны үз өстенә алган очракта)

5. Минзәлә муниципаль районының муниципаль хосусыйлыгына караган мәдәни мирас объектына карата ташламалы аренда түләве уздырылган аукцион нәтиҗәләре буенча канәгатьләнерлек булмаган хәлдә табылган мәдәни мирас объектларын арендага алу килешүе төзелгән көннән билгеләнә.

Гамәлдәге пунктның беренче абзацы нигезендә билгеләнгән ташламалы аренда түләвенең күләме, канәгатьләнерлек булмаган хәлдә дип табылган мәдәни мирас объектына аренда килешүенең гамәлдә булу срогы тәмамланмыйча торып, үзгәрә алмый.

6. Арендатор мәдәни мирас объектларын саклау буенча үз бурычларын 2014 елның 25 июнендә кабул ителгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында"гы №73-ФЗ Федераль законының 47.6 маддәсендә каралганча тулысынча үтәгәннән соң (мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән 7 елдан артмаган срокта, мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен әзерләү һәм килешү срогын да кертеп, объектны арендага тапшырган көннән 2 елдан артмаска тиеш), арендатор арендага алынган милкен субарендага (поднаем) тапшыру һәм арендага алынган милекне Россия Федерациясе законнары нигезендә арендага бирүченең язмача хәбәре булган очракта, бушлай файдалану хокукын ала.

7. Арендаторның мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен әзерләү һәм килешү мөмкинлеге булмавын раслаучы хәл килеп туган очракта (арендага тапшырылган көннән 2 елдан соңармыйча, яисә күрсәтелгән мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән соң 7 елдан артмаган срокта сак бурычлары нигезендә мәдәни мирас объектларын саклау буенча эш алып барырга), 2014 елның 25 июнендә кабул ителгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында"гы №73-ФЗ Федераль законының 47.6 маддәсендә каралганча, арендага бирүче арендаторга ачыкланган кимчелекләрне бетерү турында таләп итә.

Арендатор арендага бирүченең күрсәтелгән таләпләрен үтәмәгән очракта, соңгысы Россия Федерациясе законнары нигезендә аренда килешүен өзү турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Арендатор мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен әзерләү һәм килешү буенча бурычларын үтәмәгән очракта (мәдәни мирас объектын арендага тапшырган көннән 7 елдан артмаган срокта, мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен әзерләү һәм килешү срогын да кертеп, объектны арендага тапшырган көннән 2 елдан артмаска тиеш), арендага бирүче арендаторга аренда килешүен бер яклы өзү турында хәбәр җибәрә.

Шул ук вакытта, кимчелек арендатор тарафыннан мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләрнең үтәлмәвендә чагылса, аренда килешүен өзгәндә бәйсез гарантия суммасын арендага бирүче түләргә тиеш.

9. Арендатор аренда бирүчегә бәйсез гарантия бирә яки ала алмаган очракта, аренда килешүе Россия Федерациясе законнары нигезендә бер яклы өзелүгә дучар ителә.